**2023 елда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карау нәтиҗәләре турында.**

Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл жирлеге Советында һәм Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» гы Федераль Закон (2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» гы Татарстан Республикасы Законы (2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ ), Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мшлбагыш авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Положение турында» 2018 елның 19 июнендәге 100 номерлы Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карары белән башкарыла.

Гражданнарны шәхси кабул итү Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы тарафыннан атна саен сишәмбе 14.00 - 17.00 сәгатьләрдә, шәхсән алдан язылу буенча башкарыла.

Кабул итү көне һәм сәгатьләре, алдан язылып кую өчен телефоннар турында мәгълүмат Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырыла http://aznakayevo.tatar.ru әлеге мәгълүмат шулай ук җирле үзидарә органының Мәлбагыш авылы, Нефтяниклар урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан административ бинасында мәгълүмат стендларында урнаштырыла .

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге җирле үзидарә органында (алга таба – җирле үзидарә органы) гражданнарны кабул итүнең язылу һәм исәпкә алуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге сәркәтибе алып бара, ул гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү өчен җаваплы.

2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 нче декабренә кадәр Мәлбагыш авыл җирлеге адресына 15 мөрәҗәгать кабул ителде .

Шулардан: язма - 1 телдән-12 ;«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша -2, шәхси кабул итү вакытында - 2

Коллектив мөрәҗәгатьләр – 0

Барлык телдән мөрәҗәгатьләр татар телендә (100 %)

Мөрәҗәгатьләрнең авторлары-пенсионерлар -73,4 %, бюджет өлкәсе хезмәткәрләре 6,6 %, шәхси эшмәкәрләр – 0%, җитештерү хезмәткәрләре-6,6 %., интернет аша, "Халык контроле» системасы аша мөрәҗәгать итүче авторлар турында белешмә юк - 13,4 %

Территориаль билге буенча барлык мөрәҗәгатьләр авыл җирлегендә яшәүчеләргә туры килә.

Мөрәҗәгатьләрнең тематикасын төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияне кардан чистарту, территорияне төзекләндерү, йорт хайваннарын иректе йөртү, халыкны социаль тәэмин итү буенча) мәсьәләләре тәшкил итә .

Мәлбагыш авыл җирлегенә гражданнардан кергән язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрнең санынннан (35 мөрәҗәгать) барысына уңай чаралар һәм карарлар кабул ителде.

Авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Ахметшин

Шакирова Л.М.
37-7-91